# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге составына керүче Сабакай авылында

27.12.2021е. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге составына керүче Сабакай авылындагы гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕМ:**

1. 2022 елда Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан, 18 яшькә кадәрге 3 тән артык баласы булган гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
   - җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
   - балалар өчен уен мәйданчыклары сатып алу һәм урнаштыру;
   - урамнарны һәм ял зоналарын төзекләндерү һәм яшелләндерү;
   - һәйкәлләр төзү һәм төзекләндерү;
   - зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү;
   - суүткәргеч һәм канализация челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү.

   Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Алексеевск ш.т.б. башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.
3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Алексеевск шәһәр җирлеге» бүлегендә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары В.В. Увакинага йөкләргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы С.А. Демидов